# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Хансвер авылында

2023 елның 17 ноябре, №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Хансвер авылында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда авыл җирлегендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Хансвер авылында, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Салих авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урыны буенча өч елдан артык яшәмәгән затлардан, тыл ветераннарыннан, I һәм II төркем Инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән яисә контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләреннән, бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм иткән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән (СВО катнашучылар)дан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Хансвер авылы зиратының коймасын ремонтлау;
- кышкы вакытта Хансвер авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү һәм тоту .

3. Әлеге карарны Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә), Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга (http://bavly.tatarstan.ru),

хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru).

Гражданнар җыенында рәислек итүче З. С. Галләметдинов